**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№278**
**24.01.2020**

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу килешүләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, аларның кеременең һәм мөлкәт бәясенең максималь күләмен раслау турында

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу килешүләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, Татарстан Республикасының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Законы һәм шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу килешүләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, 2020 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләме – 14358 сум 93 тиен;

2) гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләме:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 954 432 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 1 908 864 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 2 863 296 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 817 728 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен – 4 772 160 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 5 726 592 сум;
- җиде кешедән торган гаилә өчен – 6 681 024 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен – 7 635 456 сум.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев